**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 26 февраль | № 118

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 ел, 15 июнь, 468 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 ел, 15 июнь, 468 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 20 декабрь, 1087 нче; 2011 ел, 29 июнь, 526 нчы; 2011 ел, 29 июль, 609 нчы; 2011 ел, 7 сентябрь, 747 нче; 2012 ел, 27 апрель, 330 нчы; 2012 ел, 30 июнь, 567 нче; 2012 ел, 30 июль, 645 нче; 2012 ел, 27 октябрь, 908 нче; 2013 ел, 19 март, 186 нчы; 2013 ел, 29 апрель, 296 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1111 нче; 2014 ел, 20 май, 332 нче; 2014 ел, 26 декабрь, 1939 нчы; 2015 ел, 10 март, 143 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктка түбәндәге сүзләрне өстәргә:

«, иҗтимагый берләшмәләр һәм бүтән оешмалар белән һәм үз вәкаләтләре кысаларында карарларны мөстәкыйль кабул итә»;

1.4 пунктка «банк учреждениеләре,» сүзләреннән соң «бланклар һәм» сүзләрен өстәргә;

3.2.7, 4.1.19, 4.1.21, 4.1.49, 4.2.12 пунктларны үз көчләрен югалтуын таныргa;

4.1.11 пунктка «тоташтыру» сүзеннән соң «(технологик тоташтыру)» сүзләрен өстәргә;

4.1.16 пунктта «, республиканың ягулык-энергетика балансы» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.1.17 – 4.1.18 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.17. Ивестиция программалары Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан раслана һәм тикшерүдә тотыла торган субъектлар исәбенә кертелгән электр энергетикасы субъектларының инвестиция программаларын тормышка ашыру өчен кирәкле инвестиция ресурсларын Дәүләт комитеты җайга сала торган бәяләргә (тарифларга) кертү буенча электр энергетикасы субъектлары тәкъдимнәрен бәяләү өлешендә һәм челтәр оешмаларның инвестиция программалары проектлары, бердәм милли (гомумроссия) электр челтәре белән идарә итүче оешмадан тыш, мондый челтәр оешмаларның инвестиция программаларын формалаштыру максатында Дәүләт комитеты билгеләгән ышанычлылык күрсәткечләренең һәм хезмәт күрсәтүләр сыйфатының максатлы мәгънәләренә туры килүен бәяләү өлешендә карап тикшерә;

4.1.18. Инвестиция программалары федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан раслана һәм тикшерүдә тотыла торган субъектлар исәбенә кертелгән территориаль челтәр оешмаларының инвестиция программаларын тормышка ашыру өчен кирәкле инвестиция ресурсларын Дәүләт комитеты җайга сала торган бәяләргә (тарифларга) кертү буенча электр энергетикасы субъектлары тәкъдимнәрен бәяләү өлешендә һәм челтәр оешмаларның инвестиция программалары проектлары, бердәм милли (гомумроссия) электр челтәре белән идарә итүче оешмадан тыш, мондый челтәр оешмаларның инвестиция программаларын формалаштыру максатында Дәүләт комитеты билгеләгән ышанычлылык күрсәткечләренең һәм хезмәт күрсәтүләр сыйфатының максатлы мәгънәләренә туры килүен бәяләү өлешендә килештерү процедурасында катнаша;»;

4.1.32 пунктта «һәм керосин» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.1.50 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.50. Законнарда билгеләнгән очракларда территориаль челтәр оешмалары өчен ышанычлылык күрсәткечләренең һәм хезмәт күрсәтүләр сыйфатының планлаштырылган һәм фактагы мәгънәләрен билгели, шулай ук җылылык белән тәэмин итү объектларының ышанычлылык күрсәткечләренең һәм энергетика нәтиҗәлелегенең планлаштырылган һәм фактагы мәгънәләрен билгели;»;

4.1.65 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.65. Законнарда билгеләнгән очракларда су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә билгеләнә торган тарифларга кагылышлы өлештә кайнар су белән тәэмин итү, салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) су бүлүнең үзәкләштерелгән системалары объектларының ышанычлылыгы, сыйфаты, энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләрен раслау процедурасында катнаша;»;

4.1.71 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.71. Гомуми кулланылыштагы шәһәр яны тимер юл транспорты белән пассажирлар йөртү өлкәсендә табигый монополия субъектлары эшләренә (хезмәт күрсәтүләренә) икътисадый нигезләнгән дәрәҗәдә тарифларны, җыемнарны һәм түләүләрне, шулай ук әлеге йөртүләр өчен шәһәр янында йөргәндә пассажирлар түли торган тарифларны, җыемнарны һәм түләүләрне һәм (яки) чик (минималь һәм (яки) максималь) тарифларны, җыемнарны һәм түләүләрне билгели;»;

4.1.81 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.81. Социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм шәхси

эшмәкәрләр тарафыннан гражданнарга күрсәтелә торган социаль хезмәтләргә тарифларны һәм (яки) чик (минималь һәм (яки) максималь) тарифларны билгели;»;

4.1.94 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.94. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү өчен Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә үзенең компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча гражданнарга телдән һәм язма формада хокукый консультация рәвешендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтә.

Федераль законнарда һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең бүтән норматив хокукый актларында билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә социаль ярдәмгә һәм социаль яклауга мохтаҗ гражданнарга гаризалар, шикаятьләр, үтенечнамәләр һәм хокукый характердагы башка документлар тутыру рәвешендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтә һәм судларда, дәүләт һәм муниципаль органнарда, оешмаларда граждан мәнфәгатьләрен яклый.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.1.94[1] пункт өстәргә:

«4.1.94[1]. «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә билгеләнгән тәртиптә үзенең компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча гражданнарга телдән һәм язмача, шулай ук вәкаләтле зат тарафыннан шәхси кабул итү барышында ярдәм күрсәтә;»;

түбәндәге эчтәлекле 4.1.104 – 4.1.113 пунктлар өстәргә:

«4.1.104. «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракта конкурс документларына кертелә торган җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) дәүләт җайга салуының озак вакытлы параметрлары мәгънәләрен килештерүне гамәлгә ашыра;

4.1.105. Концессия килешүләре турында Россия Федерациясе законнарында күздә тотылган очракларда җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) дәүләт җайга салуының озак вакытлы параметрлары (концессионер эшчәнлеген җайга салуның озак вакытлы параметрлары) мәгънәләрен килештерүне, шулай ук алардагы үзгәрешләрне беренче килештерүне гамәлгә ашыра;

4.1.106. Концессия килешүләре турында Россия Федерациясе законнары һәм «Җылылык белән тәэмин итү турында» Федераль закон нигезендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә тарифларны җайга салу алымын сайлау хакында конкурсны оештыручы яки концедент карарларын килештерүне Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашыра;

4.1.107. Конкурсны оештыручы яки концедент соратуы буенча җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә конкурс документларына кертелә торган бәяләр, зурлыклар, мәгънәләр һәм параметрлар турында мәгълүматны бирә;

4.1.108. «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә арендатор тарафыннан җитештерелә һәм сатыла торган товарларга һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә җайга салына торган бәяләр (тарифлар) билгеләүне,

үзгәртүне һәм төзәтүләр кертүне тиешле бәяләр (тарифлар) билгеләү, үзгәртү һәм төзәтүләр кертү вакытында гамәлдә булган һәм федераль законнар, Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары, шулай ук Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары белән каралган кагыйдәләр буенча аренда шартнамәсе гамәлдә булу вакыты чыкканга кадәр килештерә;

4.1.109. Концессия килешүләре турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда концессионер тарафыннан җитештерелә һәм сатыла торган товарларга һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә җайга салына торган бәяләр (тарифлар) билгеләүне, үзгәртүне һәм төзәтүләр кертүне тиешле бәяләр (тарифлар) билгеләү, үзгәртү һәм төзәтүләр кертү вакытында гамәлдә булган һәм федераль законнар, Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары, шулай ук Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары белән каралган кагыйдәләр буенча концессия килешүе гамәлдә булу вакыты чыкканга кадәр килештерә;

4.1.110. «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда конкурс документларына кертелә торган тарифларны җайга салуның озак вакытлы параметрларын, ышанычлылык, сыйфат, энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләрен, тарифларны җайга салу алымын килештерә;

4.1.111. Концессия килешүләре турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда тарифларны җайга салуның озак вакытлы параметрларын, ышанычлылык, сыйфат, энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләрен, тарифларны җайга салу алымын килештерә;

4.1.112. Концессия килешүе төзү хокукына конкурсны оештыручы соратуы буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 ел, 13 май карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны җайга салу кагыйдәләре белән билгеләнгән тәртиптә «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль законның $41^1$ статьясындагы 8 өлештәге 2 – 8 һәм 13 пунктларда күрсәтелгән бәяләр, зурлыклар, мәгънәләр, параметрларны бирә;

4.1.113. «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән очракларда су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә арендатор тарафыннан җитештерелә һәм сатыла торган товарларга һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә җайга салына торган бәяләр (тарифлар) билгеләүне, үзгәртүне һәм төзәтүләр кертүне тиешле бәяләр (тарифлар) билгеләү, үзгәртү һәм төзәтүләр кертү вакытында гамәлдә булган һәм федераль законнар, Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары, шулай ук Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары белән каралган кагыйдәләр буенча аренда шартнамәсе гамәлдә булу вакыты чыкканга кадәр килештерә.»;

4.2.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2.11. Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексы нигезендә тарифларны дәүләт җайга салуы өлкәсендә вәкаләтле орган,

дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы орган функцияләрен башкара;»;

түбәндәге эчтәлекле 4.2.18$^{1}$ һәм 4.2.18$^{2}$ пунктлар өстәргә:

«4.2.18$^{1}$. Тарифларны җайга салу өлкәсендә федераль башкарма хакимият органына «Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе субъектында төрле яклап субсидияләү зурлыгы һәм аны этаплап киметү турында мәгълүмат тапшыра;

4.2.18$^{2}$. Җылылык белән тәэмин итү оешмалары, җылылык челтәре оешмалары, җайга салу органнары тарафыннан мәгълүматны ачу стандартлары нигезендә һәм күрсәтелгән оешмалар эшчәнлегенең тармак, технологик, структур, географик һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алып, җылылык белән тәэмин итү оешмалары, җылылык челтәре оешмалары тарафыннан ачык файдаланууда булган мәгълүматны тапшыру формаларын һәм җылылык белән тәэмин итү оешмалары, җылылык челтәре оешмалары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган мәгълүматны тапшыру формаларын тутыру кагыйдәләрен расларга хокуклы;»;

6.6 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Идарә составына вәкаләтләрен бүтән затларга тапшыруга хокуксыз, җиде кешедән артмаган санда Дәүләт комитеты хезмәткәрләре һәм монополияго каршы органның бер вәкиле, ә электр энергетикасы өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) җайга салу мәсьәләләре буенча карарларны карап тикшергәндә һәм кабул иткәндә – шулай ук базар советыннан бер вәкил керә. Монополиягә каршы орган вәкиле Идарә составына киңәшү тавышы белән керә (тавыш бирүдә катнашмый).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\118.docx